ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 035 от « 13 » 05 2020 г.

Мамадыш муниципаль районы башлыгының
2016 елның 10 ноябрендә кабул ителгән
112 нче санлы карарына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү хакында

Мамадыш районы прокуратурасының 2020 елның 21 апрелендәге № 02-08-02-2020 санлы протесты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 28 декабрендәге 1934 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 10 ноябрендәге 480 нче карары нигезендә һәм Мамадыш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы эшчәнлеген алга таба камилләштерү максатларында к а р а р б и р ә м :

1. Муниципаль район башлыгының 2016 елның 10 ноябрендә кабул ителгән «Мамадыш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 112 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Территориаль гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы (ТСЧС) координацион органнары булып торалар:

* Мамадыш шәһәре һәм Мамадыш муниципаль районы территориясен үз эченә алган территориаль дәрәҗәдә - ТР Мамадыш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе;

* Объект дәрәҗәсендә - Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе, аның вәкаләтләренә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү керә.

2.Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе И.М. Дәрҗемановка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.П.Иванов

000041